РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Староалпаровского сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлеге
Башкарма комитеты

Адрес: 422877, РТ, с. Старое Алпарово , ул. Северная, д.29
тел:8(84346) 72553

Адресы: 422877, РТ, Иске Алпар авылы, Тоньяк ур. 29 й.
тел: 8(84346) 72553

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Иске Алпар ав.** **КАРАР**

«30» июль 2025 ел № 14

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урынын) билгеләү, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның «22» мартындагы 4 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 28.12.2020 елның № 2314 "Җитештерү һәм куллану калдыклары белән тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында" Карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге башкарма комитеты

**Карар бирә**:

1. Иске Алпар авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Алпар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урынын) билгеләү, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында" 2023 елның «22» мартындагы 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

"1.1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар тупланган урынның урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә."

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Алпар авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Р. Сәлахов